ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гоголя, д.1, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Гоголь урамы, 1 йорт, Акбаш авылы, 423958

Тел./факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 13** **« 15 » июня 2020 г.**

2020 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең
бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законга, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль законга, 2020 елның 29 гыйнварындагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында»гы 61 санлы карарына, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законына таянып, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 196 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары», «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 10 санлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. "2020 елның 15 июненнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә православие йоласы буенча җирләүгә гарантияле хезмәт күрсәтү исемлеге" турындагы 1 кушымта һәм "2020 елның 15 июненнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә мөселман йоласы буенча җирләүгә гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге» турындагы 2 кушымта нигезендә 2020 елның 15 июненнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә 6 124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 гыйнварындагы «2020 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 3 санлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге территориясендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга:

http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында, Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы

вазыйфаларын башкаручы: Л.Р.Синагатуллина

2020 елның «15»июнь 13 санлы
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге Башкарма
комитеты карарына
1 кушымта

2020 елның 15 июненнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә православие йоласы буенча җирләүгә гарантияле хезмәт күрсәтү исемлеге

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәк булган документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 530,46 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка кадәр алып бару | 718,89 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2 875,51 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

2020 елның «15 »июнь 13 санлы
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге Башкарма
комитеты карарына
2 кушымта

2020 елның 15 июненнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә мөселман йоласы буенча җирләүгә гарантияле хезмәт күрсәтүнең бәясе

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү ( сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәк булган документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле әйберләрне биреп тору һәм илтеп бирү | 1950,15 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка кадәр алып бару | 718,89 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2 875,51 |
| 5. Гәүдәне төрү | 580,31 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |